ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2021 Казан шәһәре № 90

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2019 елның 1 ноябрендәге 173 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясының 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган Вазыйфаи затларны һәм Россия Федерациясе гражданнарын дәүләт сере белән эш итүгә кертү тәртибе турында күрсәтмә нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 173 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2019 елның
1 ноябрендәге 173 номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасының
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2021 елның
4 июнендәге 90 номерлы
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.
2. Кадрлар һәм юридик эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты.